**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
## КАРАРЫ

2015 елның «12» февраленнән № 41-238

**«Яңа Чишмә муниципаль район Советының «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Яңа Чишмә муниципаль районының бюджеты турында» 2014 елның 16 декабрендәге 38-223 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 пунктының 4 абзацы нигезендә төзелгән килешүләрдән чыгып, вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыруга бәйле рәвештә Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

Яңа Чишмә муниципаль район Советының «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Яңа Чишмә муниципаль районының бюджеты турында» 2014 елның 16 декабрендәге 38-223 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Карарның 12 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа пунктлар белән тулыландырырга:

«12.1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге чараларын тәэмин итүгә төзелгән килешүләр нигезендә 2015 елга җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга, Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен 1714,4 мең сум күләмендә, әлеге карарның 21 нче кушымтасы нигезендә, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге чараларын тәэмин итүгә 1714,4 мең сум күләмендә бюджетара трансфертлар күләмен исәпкә алырга.. Авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына җирлек бюджетларында әлеге пунктта күрсәтелгән бюджетара трансфертларны күздә тотарга.

12.2. Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына 2015 елга җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга әлеге карарның 22 нче кушымтасы нигезендә 64,2 мең сум күләмендә күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен исәпкә алырга. Авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына җирлек бюджетларында әлеге пунктта күрсәтелгән бюджетара трансфертларны күздә тотарга.

12.3. Әлеге карарның 23 кушымтасы нигезендә, Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына җирлектә яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүгә, шул исәптән 2015 елга гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле керү мөмкинлеген тәэмин итүгә вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруга күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен 303,1 мең сум күләмендә исәпкә алырга. Авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына җирлек бюджетларында әлеге пунктта күрсәтелгән бюджетара трансфертларны күздә тотарга.

Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына әлеге пунктларда каралган бюджетара трансфертлар квартал саен тигез өлешләрдә башкарыла дип билгеләргә.»

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципального района — В. М.Козлов

Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2015 елның 12 февралендәге
41-238 номерлы карарына
21 нче кушымта

**2015 елга җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген тәэмин итүгә бюджетара трансфертлар**

| Авыл җирлеге исеме | Барлыгы |
|---|---|
| Акъяр авыл җирлеге | 6,9 |
| Архангел авыл җирлеге | 10,0 |
| Акбүре авыл җирлеге | 10,7 |
| Буревестник авыл җирлеге | 5,2 |
| Екатерина авыл җирлеге | 9,1 |
| Зирекле авыл җирлеге | 15,5 |
| Кызыл Октябрь авыл җирлеге | 12,1 |
| Ленино авыл җирлеге | 10,0 |
| Яңа Чишмә авыл җирлеге | 1500,0 |
| Петропавел авыл җирлеге | 20,0 |
| Тубылгы Тау авыл җирлеге | 13,2 |
| Әдәмсә авыл җирлеге | 29,0 |
| Черёмухово выл җирлеге | 13,6 |
| Чабаксар авыл җирлеге | 7,3 |
| Шахмай авыл җирлеге | 51,8 |
| **Барлыгы:** | **1714,4** |

Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2015 елның 12 февралендәге
41-238 номерлы карарына
22 нче кушымта

**2015 елга халыкны җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыруга бюджетара трансфертлар**

(мең сумнарда)

| Авыл җирлеге исеме | Барлыгы |
|---|---|
| Акъяр авыл җирлеге | 6,9 |
| Буревестник авыл җирлеге | 5,2 |
| Екатерина авыл җирлеге | 9,1 |
| Кызыл Октябрь авыл җирлеге | 12,1 |
| Ленино авыл җирлеге | 10,0 |
| Черёмухово выл җирлеге | 13,6 |
| Чабаксар авыл җирлеге | 7,3 |
| **Барлыгы:** | **64,2** |

Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2015 елның 12 февралендәге
41-238 номерлы карарына
23 нче кушымта

**2015 елга гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына гражданнарның иректле үтемлелеген тәэмин итүне дә кертеп, җирлектә яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыруга һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүгә бюджетара трансфертлар.**

(мең сумнарда)

| Авыл җирлеге исеме | Барлыгы |
|---|---|
| Архангел авыл җирлеге | 10,0 |
| Акбүре авыл җирлеге | 10,7 |
| Буревестник авыл җирлеге | 5,2 |
| Екатерина авыл җирлеге | 9,1 |
| Зирекле авыл җирлеге | 15,5 |
| Кызыл Октябрь авыл җирлеге | 12,1 |
| Ленино авыл җирлеге | 10,0 |
| Яңа Чишмә авыл җирлеге | 190,0 |
| Петропавел авыл җирлеге | 20,0 |
| Тубылгы Тау авыл җирлеге | 13,2 |
| Чабаксар авыл җирлеге | 7,3 |
| **Барлыгы:** | **303,1** |